**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская,
дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**“ 27 ” гыйнвар 2023 ел.** **№ 167**

Әтнә район Советы 2022 елның 29 мартында №120, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр керту

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, 02.03.2007 елдагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» федераль закон, 25.06.2013 №50-ТРЗ Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында Кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 № 182 карары "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына үзгәрешләр 24.04.2018 №281, 14.06.2018 №481, 17.10.2018 №490, 29.12.2018 №1320, 17.11.2021 №1087, 13.12.2021№881, 17.09.2022 №1015) Әтнә район Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Әтнә район Советының 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

карарның 3 пунктында яңа редакциядә абзацны өстәргә һәм түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3. Расларга:

- үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыкларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Тикшерү-хисап органнары рәисләрен айлык акчалата бүләкләү күләмнәре, 2 нче кушымта нигезендә.
- Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре, 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Г. Г. Хәкимов

3 нче кушымта
Әтнә район Советы карарына
№167 «27» гыйнвар 2023ел.

Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме

| Наименование должности | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Унберенче группа | Уникенче группа |
| Муниципаль район башлыгы | 19039 | 17390 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 13681 | 12689 |
| Депутат | 12688 | 12688 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 12688 | 12688 |